**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс (85552) 3-44-14,E-mail:aktanysh@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ __________

2019 елга Актаныш муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 30 декабрендәге 1096 номерлы «Татарстан Республикасы мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 1096 номерлы карары һәм «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нгезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2019 елга түбәндәгеләрне растарга.

Актаныш муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар; Актаныш муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналарның түләү күләме.

2. Актаныш муниципаль районының финанс-бюджет палатасында әлеге карарның пункты белән расланган мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативлары нигезендә мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрен финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль мәсьәләләр буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Л.Ф.Нурлыевага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе И.Ш.Бариев